| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 03 » 11 2020 № 690

Аксубаево

2021 елга «Аксубай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү
оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 10 декабрендәге 326 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.2021 елга, кушымта итеп бирелә торган, «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2.«Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Финанс бюджет палатасына мәгариф оешмаларын,

«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,

әлеге карарның 1 пункты белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль
районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең
«03» 11 2020 № 690
карары белән расланган

«Аксубай муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92851 |
| | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139227 |
| | авыл җирлеге | 143701 |